Республики Татарстан
Исполнительный комитет
Старокаширского сельского
поселения Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлеге
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

25.12.2024

№ 26

Административ регламентны раслау
турында муниципаль хезмәт күрсәтүләр
белешмә (өземтә) бирү буенча

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга;
2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге Башкарма комитетының «белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 25.06.2021 ел, №9 карарын үз көчен югалткан дип таныргa.
3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча Интернет урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru/.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сарман муниципаль районы
Иске Кәшеравыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р.Н.Дәүләтҗанов